ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.02.2025 г. Заинск №80

**«Арендалана торган мөлкәтне милеккә сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендалый торган күчемле һәм күчемсез мөлкәтне бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 15 августындагы 1415 номерлы «РФ Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» карарына таянып, Зәй муниципаль районы Уставы белән, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Арендалана торган мөлкәтне милеккә сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендалый торган күчемле һәм күчемсез мөлкәтне бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын кушымта нигезендә расларга.
2. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 9 июнендәге 427 номерлы «Арендалана торган мөлкәтне милеккә сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендалый торган күчемле һәм күчемсез мөлкәтне бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш, сәнәгать, сәүдә, эшкуарлыкка ярдәм буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Э.Э.Галеев**

Р.Р. Шәйхиев
2 80 31